# Татар теле һәм әдәбияты буенча дәүләт йомгаклау аттестациясе: форма һәм эчтәлек



# Электрон ресурс

[https://education.bashkortostan.ru/activity/38419/](https://education.bashkortostan.ru/activity/38419/)

# Бәяне төшергәне

# БУШ БИТ




## Бәяне төшергәне

# Кайбер җавапларның юклыгы




# Кодификатор турында бер ике сүз

Кодификатор – биремнәр төзү өчен нигезләмә булып тора.

Ул документта чагылыш тапмаган белем элементлары, укучы эшли белергә тиеш күнекмәләр системасы тикшерелми.

КИМнарда шул кодификаторга ярашлы төзелә.

# Вакыт

Телдән дә әдәбияттан да имтихан өчен 180 минут каралган.

Вакыт – иң зур байлык. Укытучыларга укучыларны шул вакытны дөрес итеп файдаланырга өйрәтергә кирәк.

# Яңа форма һәм эчтәлек
# Туган тел

Һәр төр оешмада туган телдән – 21 сорау.

Телнең бар баскычлары буенча (фонетика, лексика, морфология, синтаксис)

Сораулар гадидән катлаулыга таба.

# Яңа форма һәм эчтәлек
# Туган тел

## БЕРЕНЧЕ ӨЛЕШ

Сорау һәм дүрт җавап варианты.

Беренче өлештә дүрт җавапның 1се генә дөрес (дөрес җавап бер балл)




1. Күзлек сүзендә ничә сузык аваз бар?

А)1 В) 3

Б) 2 Г) 4

2. Сөйләмнең иң кечкенә берәмлеген дөрес билгеләгез.

А) Иҗек В) Җөмлә

Б) Сүз Г) Текст

3. Сингармонизм законына буйсынмаган сүзне табыгыз.

А) Чәчкә В) Карак

Б) Кырык Г) Китап

4. Кара сүзенең антонимын табыгыз.

А) Ак В) Зәңгәр

Б) Алсу Г) Яшел

5. Уңган сүзенең синонимын дөрес билгеләгез.

А) Куркак В) Тырыш

Б) Олы Г) Тиз

# Яңа форма һәм эчтәлек
# Туган тел

## ИКЕНЧЕ ӨЛЕШ

## ТЕКСТ

Сораулар бар, җаваплар юк.

Һәр дөрес җавап 3 балл бирә.




# Ябалак

(1) Ябалак – төнге ерткыч кош. (2) Ул, нигездә, агачлы урыннарда һәм кайвакыт чормаларда яши. (3) Ябалакның да, көндезге ерткычларныкы кебек, томшыгы ыргак сыман бөгелгән, бармаклары озын һәм көчле, тырнаклары шулай ук бөгелгән була. (4) Тәнен куе, ләкин көпшәк каурый япмасы каплаган. (5) Ул тавышсыз оча. (6) Каурыйлары соры-көрән төстә. (7) Күзләре зур, караңгыда күрә. (8) Бик яхшы ишетә. (9) Барлык кошлар арасында бары ябалакның гына колак яфраклары бар. (10) Ауга төнлә чыга. (11) Табышын тавышы буенча таба. (12) Тычкан (...) куян (...) тиен (...) керпе (...) вак кошлар белән туклана.

11. Әйтелү максаты ягыннан 1 нче җөмләнең төрен билгеләгез.

12. 2 нче җөмләдә **чормаларда** сүзе нинди килештә килгән?

13. 3 нче җөмләдә ***томшыгы ыргак сыман*** *бөгелгән* сурәтләү чарасы кулланылган. Сурәтләү чарасының төрен билгеләгез.

14. 4 нче җөмләдә **куе** сыйфаты нинди дәрәҗәдә килә?

15. 5 нче җөмләдә алмашлыкны табып яз.

# Яңа форма һәм эчтәлек
# Туган тел

## Өченче өлеш

Ниндидер мәкаль, әйтем, фразеологик берәмлек бирелә. Укучы язма рәвештә аның мәгънәсен ачып салырга тиеш (Язма 10 җөмләдән артмаска, хатасыз, фикер бирелеше тыгыз булырга тиеш).

# МИСАЛ

Кояш җирне яктырта, уку – кешене. Бу юлларны ничек аңлыйсыз? 10 җөмлә белән җавап бирегез.

# татар теле

**Тикшерелә торган материалның эчтәлеге**

**Тел материалы**

- 1.1. Фонетика. Татар телендә авазлар системасы.
- 1.2. Лексикология. Татар теленең сүзлек составы.
- 1.3. Сүз ясалышы. Татар телендә сүз ясалыш ысуллары.
- 1.4. Морфология. Татар телендә сүз төркемнәре.
- 1.5. Синтаксис. Гади җөмлә синтаксисы. Кушма җөмлә синтаксисы.
- 1.6. Пунктуация. Татар телендә тыныш билгеләрен кую кагыйдәләре.

**Язу**

- 2.1. Татар теленең орфографик принциплары.
- 2.2. Татар теленең орфографик нормалары
- 2.3. Тел-сурәтләү чаралары, телнең байлыгы

# Туган әдәбият

Имтихан формасы – текст өстендә эш.

Эчтәлеге: текст (проза, поэзия, драматургия).

Текстка карата 10 сорау бирелә. Укучы шул сорауларга җавап бирергә тиеш.

10 сорау арасында 2 авыр сорау. 1 сорау уртача авырлыкта, 7 сорау җиңел сораулар.




# Сораулар табигате

Текстның исеме

Текстның авторы, биография, тормыш һәм иҗат юлы

Идея, тема, проблема

Образлар системасы, характеристика

Композиция

Сурәтләү чаралары

# 10 нчы сорау

Тексттан алынган я текстның темасына, проблемасына якын җөмлә бирелгән. Укучы шул җөмләнең мәгънәсен ачып салырга тиеш (10 җөмлә, иҗадилык, фантазия, фикер тыгызлыгы хуплана, язмада хата да булмаска тиеш).




1.1. Сүз сәнгате буларак матур әдәбият.
1.2. Фольклор. Фольклор жанрлары.
1.3. Әдәби образ. Образлар системасы. Образларның төрләре. Персонаж. Характер. Тип. Автор образы. Лирик герой.
1.4. Эчтәлек һәм форма.
1.5. .Әдәби төрләр: проза, лирика, драма. Әдәби жанрлар.
1.6. Тема. Проблема. Идея. Конфликт.
1.7. Сюжет һәм сюжет элементлары: экспозиция,төенләнеш, кульминация, чишелеш, эпилог, пролог.
1.8..Әдәби әсәрләрнең теле. Әдәби әсәрдә тел-сурәтләү чаралары: лексик чаралар (синоним, омоним, антоним, фразеологизм һ.б), фоник чаралар (аллитерация, ассонанс һ.б), стилистик чаралар (инверсия, кабатлау, антитеза һ.б), троплар (чагыштыру, метафора, метонимия, аллегория, эпитет, сынландыру һ.б).
1. 9. Әдәби чор. Әдәби әсәрдә вакыт һәм урын бирелеше.
1.10. Әдәби агым. Иҗат методлары. Реализм һәм романтизм. Модернизм.

# ИГЪТИБАРЫЗ ӨЧЕН РӘХМӘТ

nachalo4ka.ru